КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 май г.Казань № 365

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2015 ел, 4 ноябрь, 835 нче; 2020 ел, 29 июнь, 540 нчы; 2021 ел, 18 июнь, 479 нчы; 2023 ел, 28 август, 1030 нчы; 2023 ел, 8 декабрь, 1578 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 пунктның беренче абзацы үз көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче; 2016 ел, 18 июнь, 413 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 705 нче; 2019 ел, 8 февраль, 82 нче; 2020 ел, 10 февраль, 84 нче; 2021 ел, 8 июнь, 441 нче; 2022 ел, 19 февраль, 138 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1324 нче; 2023 ел, 16 март, 260 нчы; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 3 июль, 779 нчы; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.5 пунктның 3.5.6 пунктчасында «махсус хәрби операция үткәрүдә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының» сүзләреннән соң «Россия Федерациясенең

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча Тикшерү комитетының тикшерү идарәсенә күчерү тәртибендә вазыйфага билгеләнгән Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләренең,» сүзләрен өстәргә;

4.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тиешле хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалануга ихтыяҗы алар күрсәтелү мөмкинлегеннән артыграк булган очракта, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүче тарафыннан формалаштырыла торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче; 2023 ел, 24 февраль, 182 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 19 октябрь, 1323 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 31 гыйнвар, 50 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүче һәм социаль хезмәтләр күрсәтелүче арасында ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5еннән дә соңга калмыйча, хисап чоры дәвамында бирелгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәтләрне тапшыру-кабул итү акты төзелә һәм аңа кул куела.»;

1.1.4 пунктның 26 пунктчасында «махсус хәрби операция үткәрүдә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының» сүзләреннән соң «Россия Федерациясенең Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча Тикшерү комитетының тикшерү идарәсенә күчерү тәртибендә вазыйфага билгеләнгән Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләренең,» сүзләрен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1293 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең илле бишенче абзацында «махсус хәрби операция үткәрүдә катнашучы гражданнарның» сүзләреннән соң «Россия Федерациясенең Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча Тикшерү комитетының тикшерү идарәсенә күчерү тәртибендә вазыйфага билгеләнгән Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләренең,» сүзләрен өстәргә;

3.1.1 пункт таблицасының $7^1$ пунктындагы 2 графасында татар текстында «гражданнар» сүзләреннән соң «Россия Федерациясенең Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе буенча Тикшерү комитетының тикшерү идарәсенә күчерү тәртибендә вазыйфага билгеләнгән Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләре,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин